# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

«Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Осинники авыл җирлеге»муниципаль берәмлегенең Осинники торак пунктында 2024 елда гражданнарның үзара салымнарын кертү турында

2023 елның 17 ноябрендәге №1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында " 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына ярашлы рәвештә, «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Осинники авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Осинники торак пунктында гражданнар җыены:

1. 2024 елда «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Осинники авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Осинники торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 700 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:
- су белән тәэмин итү һәм су чыгару системасын, су күтәрү манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (шул исәптән су өчен савыт сатып алу).

3. Әлеге карарны Осинники авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.:
- Осинники бистәсе, Яшьләр урамы, 9А йорт (административ бина);
- Осинники бистәсе, Урман урамы, 2 нче йорт (Осинники СДК),
шулай ук Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында, хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 5 көн эчендә бастырып чыгарырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы
Осинники авыл җирлеге башлыгы А. Х. Сәгъдиев